РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**

**сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**ИСКЕ КАЗИЛЕ**

**авыл җирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**3 декабрь 2019 ел** **№ 55**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Иске Казиле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Иске Казиле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 1 этабын 2019 елнын 13 нче декабренэ 13.00 сэгатькэ билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Иске Казиле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 2 этабын 2019 елнын 15 нче декабренэ 10.00 сэгатькэ билгеләргә

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Иске Казиле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм

җыелган акчаларны,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

- Иске Казиле авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу һәм Яңа ел бизэклэре сатып алу;
- Күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, триммер һәм бензин пычкысы сатып алу;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру.

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе:
а) беренче этапта Эш (хезмәт) графигы кемгә мөмкинлек бирә, эш көннәрендә кем катнаша ала, шул яшәүчеләр катнашалар.
б) икенче этапта Эш (хезмәт) графигы эш көннәрендә катнашырга мөмкинлек бирмәгән яки шәхси (гаилә) шартлары аркасында катнаша алмаган халык катнаша ала.
5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　　　И.Х.Сәгдиев